**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ 03.09.2020 № ________

ПР-162

Актаныш велосипед клубы турында Нигезләмәне раслау хакында

Велосипедны актив ял итү чарасы буларак популярлаштыру, аралашу,тәҗрибә уртаклашу һәм уртак чаралар оештыру өчен Актаныш велосипедчыларын берләштерү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш велосипед клубы турындагы Нигезләмәне расларга.
2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеген Актаныш велосипед клубын оештыру һәм гамәлгә кертү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://aktanysh.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 0180CD78000CAB95AA4750138BB28C9CD3
Владелец: Габдулхаев Ильшат Ильфатович
Действителен с 21.11.2019 до 21.02.2021

Җитәкче И.И.Габ дулхаев

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган
_____ ___________ № ___

**Актаныш велосипед клубы турында нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр.**

1. Актаныш велосипед клубы (алга таба-ВЕЛОКЛУБ) актив ял итү чарасы буларак велосипедны популярлаштыру, аралашу, тәҗрибә уртаклашу һәм уртак чаралар оештыру максатыннан оештырылган. Велоклуб үз эшен киң инициатива һәм иҗтимагый активның үзэшчәнлеге, аның җитәкче органнарын сайлау һәм клубның гомуми җыелышы алдында хисап бирү нигезендә алып бара.

Велоклуб коллегиаль, киңәшмә һәм консультатив орган булып тора.

**2. Клубның төп бурычлары.**

Велоклуб:
· велосипедта актив ял итүгә массакүләм җәлеп итүне гамәлгә ашыра;
· сәламәт яшәү рәвешен киң пропагандалый;
. үз әгъзаларын әхлакый, патриотик һәм физик тәрбияләү буенча эш алып бара.

**3. Велоклубның максаты һәм бурычы.**

3.1. Велоклуб эшчәнлегенең максаты булып физик культура, велотуризм һәм велоспортны үстерү, мәдәни һәм белем бирү дәрәҗәсен күтәрү, велоклуб әгъзаларының сәламәтлеген ныгыту һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү тора.

3.2. Велоклубның бурычы булып тора:

- Велотуризмны һәм велоспортны үстерү;
- Туган якның тарихи, табигый һәм мәдәни истәлекләрен карап, спорт походлары, сәяхәтләр, экспедицияләр һәм экскурсияләр оештыру һәм үткәрү;
- Велосипед спортының һәм спорт туризмының аерым төрләре буенча ярышлар үткәрү һәм аларда катнашу;
- Велоспорт һәм спорт велотуризмы буенча командаларны оештыру;
- Велосипед һәм туристлык кирәк-яракларын эшләү, ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү;
- Велотуризмның һәм велоспортның барлык аспектлары буенча укыту һәм белем бирү, мәдәни-тарихи аспектларны да кертеп;
- Сәламәтлекне ныгытуга юнәлдерелгән күнегүләр һәм чаралар оештыру һәм үткәрү;
- Башка клублар белән эшләү тәҗрибәсе белән уртаклашу;
- Велоклуб эшчәнлеге турында мәгълүматны интернет чыганакларда урнаштыру;
- Велосипед һәм туристлык тематикасы буенча чаралар үткәрү;

- Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;
- Халыкның киң катламнарына велокультураны алга җибәрү;
- Массакүләм чараларга велосипед сөючеләрне җәлеп итү.

## 4. Велоклуб әгъзалары, аларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Велоклуб әгъзасы булып, велоклуб эшендә катнашучы, Нигезләмәне таный торган Россия Федерациясенең теләсә кайсы гражданины булырга мөмкин.

4.2. Велоклуб әгъзасы хокуклы:

а) клуб тарафыннан үткәрелә торган велопоходларда, ярышларда, укыту семинарларында һәм башка чараларда катнашырга;

б) башка оешмалар уздырган ярышларда, велоклуб командасы өчен чыгыш ясарга һәм клуб символикасын кулланырга;

в) велоклуб эшендә шәхсән катнашырга.

г) велоклуб Советына сайларга һәм сайланырга;

д) велоклуб әгъзаларына кабул иткәндә киңәшче булырга һәм велоклубтан төшереп калдыру турында үтенеч бирергә;

е) велоклуб җыелышларында, велоклуб Советы утырышларында, интернетта велоклубның гамәли эшчәнлеге мәсьәләләре турында иркле фикер алышырга, тәкъдимнәр кертергә, ачыктан-ачык әйтергә һәм велоклуб карары кабул ителгәнче үз фикереңне якларга.

4.3. Велоклуб әгъзасы велоклуб эшендә катнашырга бурычлы. Велолуб эшендә катнашуда барлык чараларда, велопоходларда һәм ярышларда катнашуны яисә устав бурычларын велоклуб белән үтәүдә теләсә нинди ярдәм күрсәтүне аңлыйлар.

4.4. Велоклуб әгъзаларына кабул итү бары шәхси тәртиптә генә башкарыла. Велоклубка 12 яшькә җиткән затлар кабул ителә. Керүчеләрнең һәркайсы велоклубка кабул итү үтенече белән анкета-гариза тутыра. Велоклуб әгъзаларын кабул итү турындагы мәсьәлә велоклуб Советы утырышында хәл ителә; аның карары, әгәр аның өчен Совет әгъзаларының кимендә яртысы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала һәм шул көннән үз көченә керә.

4.5. Велоклубта клубта әгъза булуын раслаучы клуб карточкасы эшли. Велоклуб әгъзаларын исәпкә алу тәртибе велоклуб Советы тарафыннан билгеләнә.

4.6. Бурычларны үтәмәгән, велоклуб белән элемтәне югалткан һәм башка җитешсезлекләр өчен велоклубның әгъзасы велоклубтан чыгарылырга мөмкин. Төшереп калдыру турындагы мәсьәләне караганда, велоклуб әгъзасына белдерелгән гаепләрнең нигезле булуын җентекләп тикшерү тәэмин ителергә тиеш. Велоклубтан чыгару мәсьәләсе велоклубның гомуми җыелышы тарафыннан хәл ителә.

## 5. Клуб эше белән җитәкчелек итү.

Клубның иң югары органы-җыелыш (исемлек составының яртысыннан да ким булмаган өлеше), ул клуб президентын яшерен тавыш бирү һәм клуб идарәсен ачык тавыш бирү юлы белән сайлый. Клуб идарәсе үз составыннан ике президент урынбасарын (хуҗалык эшләре һәм экспедиция эшләре буенча), шулай ук секретарьне сайлый. Клуб идарәсе утырышы кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла.

Клуб идарәсе клубның барлык эшчәнлеген планлаштыру, үткәрү һәм исәпкә алып җитәкчелек итә. Велоклуб идарә һәм югарыдагы оешма тарафыннан расланган планнар буенча үз эшен башкара. Велоклубның эмблемасы, значогы, вымпелы һәм флагы бар.

## 6. Велоклуб эшчәнлеген матди-техник тәэмин итү

6.1. Велоклуб эшчәнлеге велоклуб һәм мәктәп әгъзаларының финанс һәм матди-техник ресурслары белән тәэмин ителә.

6.2. Утырышлар, җыелышлар, уку дәресләре өчен «Батыр» универсаль спорт комплексы биналары һәм территориясе файдаланыла.

6.3. Чараларны оештыру һәм уздыру, стоянкалар урнаштыру өчен клуб әгъзаларының һәм иганәчеләрнең акчалата иганәләре җәлеп ителергә мөмкин.

6.4. Акчалата иганәләрне исәпкә алу клуб советы тарафыннан алып барыла, ул гомуми җыелыш алдында елына бер тапкыр хисап тота.

6.5. Экипировка һәм транспорт чарасы (велосипед) клуб әгъзаларында бар, кирәк булган саен, клуб әгъзалары яки аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан үз акчаларына сатып алына.